| | | |
|---|---|---|
| «Рассмотрено»<br><br>Руководитель МО<br>_________ /Ярхамова Ф.Ф./<br>Протокол №1<br>от 27.08.2020 г. | «Согласовано»<br>Заместитель директора по ВР<br>МБОУ «Гимназия №155»<br>_________ /Бурханова А.И./<br><br>от 27.08.2020 г. | «Утверждаю»<br>Директор<br>МБОУ «Гимназия №155»<br>_________ Фазылов Н.Р.<br>Приказ № 85-0<br>от 28.08 2020 г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
**кружка «Идел дулкыннары»**

**Руководитель**

**Фатхутдинова Альбина Акдасовна**
МБОУ «Гимназия №155 с татарским языком обучения»
Ново-Савиновского района г. Казани

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол №1
от «28» августа 2020 г.

2020-2021 учебный год

## Аңлатма язуы

“Идел дулкыннары” иҗат түгәрәге укучыларны халкыбызның рухи-әхлакый кануннары белән таныштырырга, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтне үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерү юнәлешендә эш алып бара. Түгәрәктә танып-белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла. Укучылар түгәрәктә газета-журналлар басу технологиясе, газета әсәрләре иҗат итү баскычлары (тема табу, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү, текст төзү, ритм, рифма һ.б.) журналистика жанрлары турында мәгълүмат алалар. Үзләре газета-журналлар өчен шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр иҗат итәләр, үзләре язган шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнәләр. “Идел дулкыннары” исемле гимназия газетасын чыгаралар. Иҗат түгәрәгенең эшчәнлеген шул газета битләрендә яктыртып баралар.

Түгәрәкнең эше утырышлар дип аталса да, ул структур яктан традицион формадагы дәресләргә охшаган: оештыру, актуальләштерү, яңа материалны аңлату, ныгыту, йомгаклау. Дәресләрдә ныгытуга, ягъни гамәли эшкә, күнекмәләр бирүгә вакытның күпчелек өлеше сарыф ителә, кайбер утырышлар тулысы белән практик эшкә багышлана. Түгәрәк лекция, практикум, иҗат ителгән әсәрләрне тәкъдим итү, проект эше яклау, очрашу-әңгәмә, экскурсия, кичә һәм башка формаларда да үткәрелә. Программа атнасына 4,5 дәрес исәбеннән төзелде. Түгәрәктә 5-6 нчы сыйныф укучылары шөгыльләнә.

**Түгәрәкнең максаты:**

-сүзнең матурлыгын, туган телнең кеше тормышындагы алыштыргысыз ролен укучыларга төшендерү;

-туган як матурлыгын күрергә, аны сакларга өйрәтү;

-укучыларны әйләнә-тирәлеккә иҗади карарга өйрәтү, аларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

- укучыларда әдәби телгә мәхәббәт тәрбияләү, дөрес сөйләргә, фикерне дөрес итеп әйтергә, аңлатырга өйрәтү.

**Түгәрәкнең бурычлары:**

- балаларны иҗади дәртләндерү, аларның йөрәгендә иҗат чишмәсен уяту;
- көндәлек матбугат белән танышып баруга күнектерү;
- республикада, шәһәрдә, сыйныфта булган яңалыклар, истәлекле вакыйгаларны өйрәнеп, вакытлы матбугат жанрының берсендә хәбәрләр язарга өйрәтү;
- түгәрәк әгъзалары тарафыннан уңышлы дип табылган әсәрләрне республикада чыгып килә торган газета-журналга тәкъдим итү;
-төрле конкурсларда катнашу, укучыларның буш вакытларын файдалы итеп үткәрүгә ирешү.

**Көтелгән нәтиҗә:**

Журналист һөнәренең серләрен үзләштерү, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләрен аңлау һәм иҗат эшенә тартылу.

Эш методлары һәм формалары:

- лекция
- практикум
- конференция
- эшлекле уен
- иҗат ителгән әсәрләрне тәкъдим итү
- проект эше яклау
- очрашу-әңгәмә
- экскурсия.

**Тематик план**

*Атнасына 9 сәгать.*

.

## “Идел дулкыннары” түгәрәге программасы

**Оештыру эшләре.** (Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү, үткән уку елында эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау)

**Газета-журнал укый беләбезме?** Газета ничек ясала? Хәбәрчегә хас сыйфатлар. Минем яраткан газетам.“Безнең гәҗит” газетасына экскурсия.
Газета алдаганны яратмый. Газеталарга күзәтүләр. Газета-журналлардагы фоторәсемнәр. Рәсем ясау, рәсемгә исем куярга өйрәтү

**Журналистикада жанр төрләре**
*Хәбәри жанрлар:* Хәбәр язарга өйрәнәбез. Гимназиядә булган вакыйга яки факт турында язу. Репортаж-күзәтче жанр. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу. Интервью – иҗади гапләшү. Хисап (отчет) –сөйләшүгә корылган вакыйга турында сөйли. *Аналитик жанрлар:* Корреспонденция-җәмәгатьчелек иътибарын проблемага юнәлтә. Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт.

**Шигырь язарга өйрәнәбез.** Шигырьдә ритм һәм рифма саклау кагыйдәләре. Күренекле шагыйрьләрнең шигырьләрен уку, шигырь төзелешен тикшерү. Уеннар "Башын башлыйм, син тәмамла”, “Җомга көн кич белән” утырышында шагыйрьләр белән очрашу. Газета-журналларда басылган шигырьләргә күзәтү ясау. Төрле темаларга шигырьләр иҗат итү, аларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау. “Идел дулкыннары” газетасын чыгару.

**Риторика-чыгыш ясарга һәм аралашырга өйрәтүче фән.** Сәнгатьле сөйли белү осталыгы. Үзебез иҗат иткән шигырьләрне сәнгатьле уку.
Иҗат түгәрәгенең ачык утырышларында, гимназиядә уздырылган башка чараларда чыгыш ясау.

**Еллык эшләргә нәтиҗә ясау.** Уку елы ахырында иҗат түгәрәгенең ачык утырышын уздыру.

**Программаны тормышка ашыру шартлары һәм көтелгән уңышлар.**

Программа түгәрәк җитәкчесеннән фәнни-педагогик әзерлеккә ия булуны таләп итә. Укытучының филология, тарих, журналистика, рәсем сәнгате буенча билгеле бер күләмдә белеме, сәләте, күнекмәләре булырга тиеш. Һәрдаим эзләнгәндә, бай материал туплап, белгечләр белән киңәшләшеп, аларны эшчәнлеккә җәлеп иткәндә, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Белем бирү программасы шактый катлаулы, шуңа күрә түгәрәккә йөрүче балаларның дәресләргә даими йөрүе кирәк. Эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: теоретик материал һәр дәрестә гамәли эш белән ныгытылырга тиеш. Укучылар үз көчләре белән нәрсәдер иҗат итсәләр, язсалар, кызыксыну арта. Шуны истә тотып, программада гамәли дәресләр өстенлек итә.

Күрсәтмә материалны мультимедиа чаралары аша файдалану уңышлы. Ул дәресне җанлырак итә, педагогның эшен бермә-бер җиңеләйтә. Әлеге программаны тулысынча тормышка ашыру өчен берләшмә утырышлары үткәрелә торган кабинетка интернет челтәренә тоташкан компьютер, ноутбук, фотоаппарат, принтер кирәк.

Курс буенча методик эшкәртмәләрнең аз булуы эштә күп кыенлыклар тудыра. Программа авторы бу юнәлештә туктаусыз эзләнү алып бара. Программа материалын уңышлы үзләштергән укучы түбәндәге белем һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш:

- гимназиядә яки группада үткәрелгән чара турында хәбәр яза;
- ритм һәм рифманы иҗат эшендә дөрес итеп куллана;
- журналистикадагы жанр төрләрен һәм үзенчәлекләрен дөрес һәм урынлы файдалана ала;
- һәр эшендә пөхтәлеккә, язмаларының дөреслегенә ирешергә омтыла;
- журналистика барлыкка килү, үсеш тарихыннан хәбәрдар, хәзерге шартларда журналистикадагы үсеш тенденцияләре белән кызыксына, яңалыкларны вакытында белеп бара;
- сүзләрдән образ тудыра, художестволы чаралар ярдәмендә иҗат итә белә;
- үзе иҗат иткән шигырьне сәнгатьле итеп сөйли;

- үз милләтенең культурасы, сәнгате һәм әдәбияты белән горурлану хисләре кичерә;
- хәзерге татар әдәби телендә аралаша һәм сәхнәдән торып сөйли белә;
- иҗади бәйгеләрдә катнаша.

| Атна саны | Тема | Сәгать саны | Үтәү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1. | Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру инструктажлар үткәрү. Үткән уку елында эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау. | 2<br>2,5 | 2.09<br>3.09 | |
| | Чишмә башын эзли китсәң… | 2<br>2,5 | 7.09<br>8.09 | |
| 2. | Газета-журнал укый беләсезме?<br>Газета ничек ясала? | 2<br>2,5 | 9.09<br>10.09 | |
| | Мәкалә язу серләре. | 2<br>2,5 | 14.09<br>15.09 | |
| 3. | Хәбәрчегә хас сыйфатлар<br>Минем яраткан газетам. | 2<br>2,5 | 16.09<br>17.09 | |
| | Кем ул хәбәрче? Журналист һөнәре нинди һөнәр ул? Журналист нинди сыйфатларны туплаган булырга тиеш? | 2<br>2,5 | 21.09<br>22.09 | |
| 4. | “Безнең гәҗит” газетасына экскурсия<br>“Салават күпере”, “Сабантуй”, “Ялкын” басмалары сайтына сәяхәт. | 2<br>2,5 | 23.09<br>24.09 | |
| | Әдәби сөйләм һәм аның стильләре | 2<br>2,5 | 28.09<br>29.09 | |
| 5. | Газета алдаганны яратмый.<br>Газеталарга күзәтүләр. | 2<br>2,5 | 30.09<br>1.10 | |
| | Яраткан укытучыларны зурлап шигырьләр, мәкаләләр иҗат итү. | 2<br>2,5 | 5.10<br>6.10 | |
| 6. | Газета-журналлардагы фоторәсемнәр.<br>Рәсем ясау, рәсемгә исем куярга өйрәтү. | 2<br>2,5 | 7.10<br>8.10 | |
| | «Көзге бал» бәйрәме мизгелләре | 2<br>2,5 | 7.10<br>8.10 | |
| 7. | “Рифмадаш сүзләр табу” уены.<br>Сурәтләү чаралары: эпитет, гипербола, литота, метафора, метонимияләрнең әһәмиятен, аларны әдәби әсәрдә куллана белергә өйрәтү. | 2<br>2,5 | 12.10<br>13.10 | |
| | Тормыш- көнкүреш әкиятләре | 2<br>2,5 | 14.10<br>15.10 | |
| 8. | “Нәрсә ул ритм?”<br>Шигъри ритм уйлату. Бергәләп шигъри куплетлар иҗат итү. | 2<br>2,5 | 19.10<br>20.10 | |
| | Шигырь- ритмлы сөйләм. Рифма, строфа, һәм шигырь интонациясе - ритмның аһәңдәше | 2<br>2,5 | 21.10<br>22.10 | |
| 9. | Шигырьдә рифма саклау кагыйдәләре.<br>Чәчмә шигырьләрне, нәсерне тезмә шигырь рәвешенә әйләндерү. | 2<br>2,5 | 26.10<br>27.10 | |
| | «Тема тапсам язар идем» | 2<br>2,5 | 28.10<br>29.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10. | “Без дә шигырь язабыз”. Укучылар иҗат иткән шигырьләрне анализлау.<br>Өстәлдәге букетка карап шигырь иҗат итү,төзәтмәләр кертү.<br>Рәсемгә яки табигать күренешенә карап, миниатюр хикәя яисә шигырь язу. | 2<br>2,5 | 2.11<br>3.11 | |
| | Исеме дә матур, җисеме дә | 2<br>2,5 | 5.11<br>9.11 | |
| 11. | М.Җәлил иҗаты, тормыш юлы буенча КВН.<br>“Уйлап тап” уены. Чайнворд чишү. | 2<br>2,5 | 10.11<br>12.11 | |
| | Үзебез табышмак чыгарабыз. | 2<br>2,5 | 16.11<br>17.11 | |
| 12. | “Әгәр мин тылсымчы булсам...” дигән тема буенча эшләү.<br>Кроссворд төзү һәм чишү. | 2<br>2,5 | 18.11<br>19.11 | |
| | Халык авыз иҗаты әсәрләреннән әкиятләр.<br>Әкиятләрнең төзелеше. | 2<br>2,5 | 23.11<br>24.11 | |
| 13. | Татар телевидениесе.<br>Татар телевидениесе турында әңгәмә оештыру. | 2<br>2,5 | 25.11<br>26.11 | |
| | Аралашу үзе сәнгать | 2<br>2,5 | 30.11<br>1.12 | |
| 14. | Татарча тапшырулар турында мәгълүмат бирү.<br>Татарча мультфильмнар карау. | 2<br>2,5 | 2.12<br>3.12 | |
| | Тылсымлы әкиятләр. | 2<br>2,5 | 7.12<br>8.12 | |
| 15. | Фольклор материалын, халык җырларын иҗади файдаланып яңа әсәр иҗат итү.<br>Татар халык әкиятләре. | 2<br>2,5 | 9.12<br>10.12 | |
| | Хайваннар турындагы әкиятләр. | 2<br>2,5 | 14.12<br>15.12 | |
| 16. | Күренекле шагыйрьләрнең шигырьләрен уку.<br>Шигырь төзелешен тикшерү. | 2<br>2,5 | 16.12<br>17.12 | |
| | Халык авыз иҗаты әсәрләреннән әкиятләр.<br>Әкиятләрнең төзелеше. | 2<br>2,5 | 21.12<br>22.12 | |
| 17. | Уеннар “Башын башлыйм, син тәмамла”.<br>Уен уйлап тап. Иҗади биремле уеннар. | 2<br>2,5 | 23.12<br>24.12 | |
| | Без үзебез мәзәкче. | 2<br>2,5 | 28.12<br>29.12 | |
| 18. | “Җомга көн кич белән” утырышында шагыйрьләр белән очрашу.<br>Газета-журналларда басылган шигырьләргә күзәтү ясау. | 2<br>2,5 | 30.12<br>11.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Җомга көн кич белән” утырышында шагыйрьләр белән очрашу.<br>Газета-журналларда басылган шигырьләргә күзәтү ясау. | 2<br>2,5 | 12.01<br>13.01 | |
| 19. | Төрле темаларга шигырьләр иҗат итү.<br>Аларны уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау. | 2<br>2,5 | 14.01<br>18.01 | |
| | Яздан аерып булмый Тукайны… | 2<br>2,5 | 19.01<br>20.01 | |
| 20. | “Идел дулкыннары” газетасына материаллар туплау.<br>“Идел дулкыннары” газетасын чыгару. | 2<br>2,5 | 21.01<br>26.01 | |
| | Иң якын дустым | 2<br>2,5 | 27.01<br>28.01 | |
| 21. | Риторика.<br>Чыгыш ясарга һәм аралашырга өйрәтүче фән. | 2<br>2,5 | 1.02<br>2.02 | |
| | Интервью | 2<br>2,5 | 3.02<br>4.02 | |
| 22. | Сәнгатьле сөйли белү осталыгы.<br>Сәхнәдә чыгыш ясау культурасы. | 2<br>2,5 | 8.02<br>9.02 | |
| | Шәфкатьлелек бизи кешене. | 2<br>2,5 | 10.02<br>11.02 | |
| 23. | Үзебез иҗат иткән шигырьләрне сәнгатьле уку.<br>Яраткан шагыйрьләрнең шигырьләрен уку. | 2<br>2,5 | 15.02<br>16.02 | |
| | Үзебез табышмак чыгарабыз. | 2<br>2,5 | 17.02<br>18.02 | |
| 24. | Журналистикада жанр төрләре белән танышу.<br>Хәбәри жанрлар. | 2<br>2,5 | 22.02<br>24.02 | |
| | Иң якын дустым | 2<br>2,5 | 25.02<br>1.03 | |
| 25. | Хәбәр язарга өйрәнәбез.<br>Гимназиядә булган вакыйга яки факт турында язу. | 2<br>2,5 | 2.03<br>3.03 | |
| 26. | Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу.<br>Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу. | 2<br>2,5 | 4.03<br>9.03 | |
| | Хезмәте барның хөрмәте бар. | 2<br>2,5 | 10.03<br>11.03 | |
| 27. | Интервью алу.<br>Иҗади гапләшү. | 2<br>2,5 | 15.03<br>16.03 | |
| | Хәбәр | 2<br>2,5 | 17.03<br>18.03 | |
| 28. | Хисап (отчет).<br>Сөйләшүгә корылган вакыйга турында сөйләү. | 2<br>2,5 | 22.03<br>23.03 | |
| | Көлке капчыгы ертылгач.. | 2<br>2,5 | 24.03<br>25.03 | |
| 29. | Корреспонденция- җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә.<br>Корреспонденция- җәмәгатьчелек игътибарын | 2<br>2,5 | 29.03<br>30.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | проблемага юнәлтә. | | | |
| | Репортаж | 2<br>2,5 | 31.03<br>1.04 | |
| 30. | Мәкалә һәм аның төрләре.<br>Үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт. | 2<br>2,5 | | |
| | Алар онытылмас… | 2<br>2,5 | | |
| 31. | Укучыларның ел буе иҗат иткән шигырь һәм хикәяләреннән газетага тәкъдим итү. Иң яшь язучылар. Аларның китаплары белән танышу. | 2<br>2,5 | | |
| | “Соңгы кыңгырау” бәйрәме мизгелләре | 2<br>2,5 | | |
| 32. | “Идел дулкыннары” газетасының чираттагы санын чыгару<br>Түгәрәкнең еллык эшенә йомгак ясау. | 2<br>2,5 | | |
| 33 | Түгәрәкнең еллык эшенә йомгак ясау. | 2<br>2,5 | | |

Пронумеровано, прошнуровано и
скреплено печатью __11__ страниц
Директор МБОУ «Гимназия №155»
__________ Н.Р.Фазылов